ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**21.02.2024**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 485**

Зеленодольск муниципаль районы территориясендә Реклама комиссиясе турында нигезләмәне раслау һәм Реклама буенча комиссия төзү турында

2006 елның 13 мартындагы «Реклама турында» 38-ФЗ номерлы Федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Зеленодольск муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 23 октябрендәге 16 номерлы карары , «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә тышкы реклама өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга салу максатларында, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә Реклама комиссиясен төзергә һәм аның составын 1 нче кушымтада каралганча расларга.
2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә Реклама комиссиясе турындагы нигезләмәне (2 нче кушымта) расларга.
3. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф.Хәбибуллин

Татарстан Республикасы
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның 21 февралендәге
485 номерлы карарына
1 нче кушымта

Зеленодольск муниципаль районының реклама комиссиясе
**СОСТАВЫ**

| | | |
|---|---|---|
| 1. | БАУЭР<br>Анастасия Сергеевна | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары - **Комиссия рәисе** |
| 2. | ШАКИРОВ<br>Марат Госман улы | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының кулланучылар базары бүлеге башлыгы - **Комиссия рәисе урынбасары** |
| 3. | ГАЛИУЛЛИНА<br>Рәзилә Рәйс кызы | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының кулланучылар базары бүлеге баш белгече - **Комиссия секретаре** |

**Комиссия әгъзалары:**

| | | |
|---|---|---|
| 4. | ШАКИРОВ<br>Дамир Илһам улы | «Зеленодольск муниципаль районының Архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесе башлыгы урынбасары - баш архитектор (килешү буенча) |
| 5. | МИНҺАҖЕВ<br>Нияз Наил улы | «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының торак-коммуналь хуҗалык департаменты» муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчесе (килешү буенча) |
| 6. | АЛЕКСАХИНА<br>Анна Юрьевна | «Зеленодольск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль учреждениесе җитәкчесе (килешү буенча) |
| 7. | МӘХМҮТОВ<br>Ирик Абдрахман улы | «Зеленодольск муниципаль районы төзелеше һәм инфраструктура үсеше департаменты» муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчесе (килешү буенча) |

Татарстан Республикасы
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның 21 февралендәге
485 карарына
2 нче кушымта

**Зеленодольск муниципаль районы территориясендә**
**Реклама комиссиясе турында нигезләмә**

## 1.Гомуми нигезләмә

1.1 Әлеге нигезләмә Зеленодольск муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру мәсьәләләре буенча комиссия (алга таба - Комиссия) төзүне һәм аларның эшчәнлек тәртибен билгели.

1.2 Комиссия гамәлдәге законнар таләпләре нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру мәсьәләләрен карау максатларында, төзелгән даими эшләүче коллегиаль орган булып тора.

1.3 Комиссия үз эшчәнлегендә гамәлдәге Россия Федерациясе законнарына, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү тәртибе турындагы нигезләмәгә, тышкы реклама өлкәсен, шулай ук әлеге нигезләмәне җайга сала торган Зеленодольск муниципаль районының муниципаль хокукый актларына таяна.

1.4 Комиссиянең төп бурычы - Зеленодольск муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру мәсьәләләре буенча килешенгән карарлар эшләү.

1.5 Куелган бурычны хәл итү өчен Комиссия түбәндәге функцияләрне башкара:

- Зеленодольск муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләренең яңа типлары һәм төрләренең тышкы күренешенә карата таләпләрне һәм техник характеристикаларын карый.
- муниципаль хокукый акт белән расланган Зеленодольск муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру схемасына үзгәрешләр кертү мөмкинлеге турындагы тәкъдимнәрне карый;
- Комиссия рәисе кушуы буенча Зеленодольск муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга кагылышлы башка мәсьәләләр карала.

1.6 Үзенә йөкләнгән бурычны гамәлгә ашыру кысаларында Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

- карала торган мәсьәләләр буенча кирәкле карарлар кабул итү өчен федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарыннан, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарыннан, Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органнарыннан, башка оешмалардан мәгълүмат соратып алырга;
- Комиссия утырышларында катнашу өчен федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнары, башка оешмалар, физик һәм юридик затлар вәкилләрен чакырырга.

## 2. Комиссиянең составы, билгеләнеше һәм функциясе

2.1. Комиссия 7 әгъзадан тора. Комиссия составына Комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасары, Комиссия әгъзалары һәм Комиссия секретаре керә.

2.2 Комиссия рәисе:

- Комиссия составына керә;
- Комиссия эшчәнлеге белән гомуми җитәкчелек итә;
- Комиссия утырышларын билгели, аларны үткәрү датасын, вакытын, формасын һәм урынын, шулай ук карау өчен чыгарыла торган мәсьәләләр компетенциясенә керә торган Комиссия әгъзаларының составын билгели;
- Комиссия утырышы көн тәртибенә чыгарыла торган мәгълүмати материалларны килештерә;
- Комиссия әгъзаларына йөкләмәләр бирә;
- Комиссия утырышы беркетмәсен раслый.

2.2.1 Комиссия рәисе булмаган очракта, аның вазыйфаларын Комиссия рәисе урынбасары - Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының кулланучылар базары бүлеге башлыгы башкара.

2.3. Комиссия рәисе функциясен Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары башкара.

2.4. Комиссия секретаре вазыйфасын Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының кулланучылар базары бүлеге хезмәткәре башкара.

## 3.Комиссия секретареның роле һәм бурычлары. Эшне оештыру һәм карарлар кабул итү

3.1. Комиссия эшен Комиссия секретаре оештыра.

3.1.1. Комиссия секретаре:

- Комиссия составына керә;
- Комиссия утырышларына кирәкле мәгълүмат материалларын әзерләүне оештыра;
- Комиссия әгъзаларына мәгълүмат материалларын таратуны оештыра;
- Комиссия утырышларын уздыруны оештыра;
- Комиссия әгъзаларыннан тәкъдимнәр, искәрмәләр, рекомендацияләр җыюны оештыра;
- Комиссия утырышы беркетмәсенә, шулай ук Комиссия утырышы беркетмәсеннән өземтәләргә имза сала;
- Комиссия утырышлары беркетмәләрен исәпкә ала һәм саклый.

3.2. Комиссия утырышлары кварталга кимендә 1 тапкыр көндезге формада, читтән торып яисә видеоконференция режимында үткәрелә.

3.3. Комиссия әгъзалары Комиссия утырышларында каралган мәсьәләләр буенча үз фикерләрен телдән яки язма формада белдерәләр. Үткәрелгән утырыш йомгаклары буенча, Комиссия әгъзаларының тәкъдимнәре Комиссия утырышы беркетмәсенә кертелә яисә беркетмәгә язма рәвештә теркәп куела. Тәкъдимнәр, искәрмәләр, рекомендацияләр булган очракта, Комиссия әгъзалары аларны Комиссия утырышы көн тәртибендә күрсәтелгән срокта тапшырырга тиеш.

3.4. Комиссия карарлары Комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә.

3.5. Комиссия карары Комиссия утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә, ул Комиссия рәисе тарафыннан раслана.

3.6. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итү Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Кулланучылар базары бүлеге тарафыннан башкарыла.